ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.02.2025 г. Заинск № 84

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 25 августындагы 662 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль яклангнлык дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән чаралар күрү максатларында һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 25 августындагы 662 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына (08.02.2024 ел, № 68, 14.03.2024 ел, № 157 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5.2. пунктның өченче абзацында **«ОВЗ белән белем алучы статусына ия инвалид балалар»** сүзләреннән соң **«ОВЗ статусыннан башка инвалид балалар»** сүзләрен өстәргә;

1.2. 5.2. пунктның дүртенче абзацында **«Махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булганнарга»** сүзләреннән соң **«яисә Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында бурычларны үтәгәндә инвалидлык алган кешеләргә яки Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашкан хәрби хәрәкәтләр ветераннарына.»**;

1.3. 5.4. пунктта **«Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларга (ОВЗ) һәм ОВЗ белән белем алучы статусы булган инвалид балаларга»** сүзләреннән соң **«Мәгариф оешмаларында белем алучы инвалид балалар, ОВЗ статусы булмаган»** сүзләрен өстәргә;

1.4. 5.6. пунктта **«ОВЗ белән белем алучы статусына ия инвалид балалар»** сүзләреннән соң **«Өйдә белем алучы ОВЗ статусы булмаган инвалид балалар»** сүзләрен өстәргә;

1.5. 5.7. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. **Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, хәрби хезмәткәрләр һәм Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче затлар арасыннан балалары, Татарстан Республикасында оештырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы**, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле рәвештә үтәүче гражданнар, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территориясендә махсус хәрби операция уздыру зонасына **командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган яки Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында бурычларны үтәгәндә инвалидлык алган югарыда күрсәтелгән категория гражданнарның балаларына**, яки Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашкан хәрби хәрәкәтләр ветераннарына ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) язма гариза буенча федераль, төбәк һәм җирле бюджеттан бюджет ассигнованиеләре исәбеннән ике тапкыр түләүсез туклану бирелә, аңа хокук билгели торган документларның күчермәсе кушыла:

- КФҮ нә мөрәҗәгать иткәндә Россия Федерациясе Дәүләт хезмәтләре порталы аша электрон рәвештә алынган, QR-коды булган яисә кәгазьдә алынган Россия Федерациясе Оборона министрлыгыннан белешмә;
- махсус хәрби операция барышында командировкага җибәрелгән һәм хәрби бурычларны үтәүче затлар өчен эш урыныннан белешмә;
- хәрби-табиб комиссиясе бәяләмәсе нигезендә медик-социаль экспертиза бюросы тарафыннан бирелгән инвалидлык турында белешмә.

Гомуми белем бирү учреждениесе укучыларга ташламалы туклану бирүдән түбәндәге нигезләрдә баш тартырга хокуклы:

- рөхсәтсез китү (РФ Җинаять кодексының 337);
- дезертирлык (РФ ҖК 338);
- сугыш хәрәкәтләрендә катнашудан баш тарту (РФ ҖК 332);
- әсирлеккә тапшыру (РФ ҖК 352.1);
- махсус хәрби операция уздыру зонасында хезмәт командировкасын тәмамлау яки Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби

хезмәткәрләрне һәм затларны, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе хезмәткәрләрен эштән азат итү;
- махсус хәрби операцияне тәмамлау.».
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 01 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сафаргалиев
3-27-42